ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОСПАССКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Молодежная, д. 13, с. Новоспасск, 423535

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА СПАС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яшьләр урамы, 13 нче йорт,
Яңа Спас авылы, Зәй районы, 42353

Телефон: 6-45-48. Электронный адрес: Nspas.Zai@tatar.ru , сайт: https://zainsk.tatarstan.ru/novospasskoe.ht

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**01 февраля 2024 г.**

**КАРАР**
**№ 3**

**2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерүнең муниципаль программасы турында**

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү, Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеге өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Яңа Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасын расларга.
2. Әлеге карарны Яңа Спас авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Н.В.Танчук**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Яңа Спас авыл җирлеге
башкарма комитетының
2024 елның 01 февралендәге
3 номерлы карарына
1 кушымта

**«2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм» муниципаль программасы**

1. **«2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм» муниципаль программасының паспорты**

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме:** | «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм программасы» (алга таба – программа). |
| **Программаны эшләү өчен нигез** | 1.«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>3. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган «2014-2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» дәүләт программасының «2018-2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы<br>5. Зәй муниципаль районының «Яңа Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы. |
| **Программаның заказчысы:** | Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты. |
| **Программаны эшләүче** | Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты. |
| **Программаның максатлары:** | - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен уңайлы мохит булдыру;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлекнең гамәлдәге субъектларын саклап калу һәм яңаларын булдыру;<br>- салым салына торган базаны киңәйтү һәм салымнар һәм җыемнар җыюны арттыру исәбенә бюджет формалаштыруга кече һәм урта эшмәкәрлекнең кертемен арттыру;<br>- базарны җирле җитештерүчеләр товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре белән баету; |

| | |
|---|---|
| | - Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге халкын эш белән тәэмин итү (алга таба - җирлек) |
| **Программаның бурычлары:** | - Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының тотрыклы эшчәнлеге өчен хокукый, икътисадый һәм оештыру шартлары тудыру.<br>- Адреслы методик, мәгълүмати, консультатив ярдәм күрсәтеп, эшмәкәрлеккә ярдәм итү инфраструктурасын үстерү<br>- Кече һәм урта бизнес субъектын үстерүгә комачаулаучы административ киртәләрне бетерү.<br>- Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме ысулларын һәм механизмнарын камилләштерү.<br>- Кече һәм урта бизнес субъектлары предприятиеләренең эшлекле һәм инвестицияләү активлыгын арттыру.<br>- Халыкның мәшгульлеген арттыру өчен шартлар тудыру.<br>- Социаль үсешнең өстенлекле юнәлешләрендә эшчәнлек алып баручы кече һәм урта бизнес субъектлары вәкилләрен җәлеп итү.<br>- Муниципаль заказ үтәүгә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын җәлеп итү |
| **Программаны гамәлгә ашыру срогы** | 2024-2026 еллар |
| **Программадан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр** | -өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече бизнеста эшләүчеләр санын арттыру;<br>- кече эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру;<br>- җитештерү күләмнәрен үстерү, продукция сату базарын киңәйтү;<br>- гаилә терлекчелек фермаларының санын, авыл хуҗалыгы терлекләренең баш санын арттыру,<br>- кече эшмәкәрлек субъектларыннан авыл җирлеге бюджетына керемнәр өлешен арттыру;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын методик тәэмин итү исәбенә югары мәгълүмати активлык һәм хәбәрдарлык булдыру;<br>- эшсезлек дәрәҗәсен киметү;<br>- хакимияткә ышанычны арттыру, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм җирле үзидарә органнары арасында эшлекле мөнәсәбәтләрне ныгыту. |
| **Программа үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы** | Авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләренә ел саен анализ ясау ярдәмендә гамәлгә ашырыла торган программаны реализацияләү мониторингы. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Елларга бүленгән программаның финанслау күләме һәм чыганаклары** | Финанслау чыганагы | ел | | | Гамәлгә ашыру чорында барлыгы |
| | | 2024 | 2025 | 2026 | |
| | Җирле бюджет | 1000,00 сум | 1000,00 сум | 1000,00 сум | 3000,00 сум |
| | Искәрмә: финанслаукүләмефаразлаухарактерындаһәммуниципаль бюджет мөмкинлекләренисәпкәалыпаңаел саентөзәтмәләркертелергә тиеш | | | | |

## 2. Гомуми нигезләмәләр

Программа авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209 - ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган «2014-2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018-2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы нигезендә эшләнде.

Программаның объекты булып кече һәм урта эшкуарлык субъектлары - юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тора. Көйләү предметы - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына муниципаль ярдәм күрсәтү.

Программаның эшчәнлек өлкәсе - авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына муниципаль ярдәм күрсәтү.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары - җирлек территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кулланучылар кооперативлары һәм коммерция оешмалары (дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләр, крестьян (фермер) хуҗалыклары. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә җирлек башкарма комитеты тарфыннан муниципаль ярдәм күрсәтү - җирлек территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен уңай шартлар тудыру буенча финанс, милек, оештыру характерындагы чаралар комплексын тормышка ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлек.

## 3. Проблеманың эчтәлеге, аны программа ысулы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыру керә. Социаль-икътисадый бурычларны хәл итүгә, беренче чиратта, яңа эш урыннары булдыру, эшсезлек дәрәҗәсен киметү, дәүләтнең социаль һәм сәяси тотрыклыгының төп гаранты - урта сыйныфны формалаштыру ярдәм итә ала.
Яңа предприятиеләр һәм эш урыннары булдыру юлы белән кече һәм урта эшмәкәрлек халыкны эш белән тәэмин итү, базарны товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү проблемасын өлешчә хәл итүне тәэмин итә. Шуның белән бергә, кече эшмәкәрлек секторына чагыштырмача түбән керемлелек, яңа технологияләрне үзләштерүдә кыенлыклар, үз ресурсларынңның чикле булуы һәм көндәшлеккә каршы тора алмау хас.

Шул ук вакытта кече һәм урта бизнес вәкилләре өлешенә туры килә торган эшмәкәрлек үсешенә тискәре йогынты ясый торган төп проблемалар булып түбәндәгеләр тора:
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына башлангыч капитал һәм әйләнештәге акча җитмәү, банк кредитлары алу белән бәйле кыенлыклар һәм алар буенча югары процент ставкалары;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен җир кишәрлекләрен һәм җитештерү мәйданнарын арендалау мөмкинлекләре чикле булу;
- ышанычлы социаль якланганлык һәм иминлек булмау;
- кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү өчен кирәкле инфраструктура булмау;
- квалификацияле кадрларга кытлык, кече бизнес өлкәсендә хезмәт хакының түбән булуы.

Соңгы елларда җирлектә кече эшмәкәрлек хуҗалык итүнең базар системасының аерылгысыз өлешенә әверелде, һәм аның үсеше тагын да зуррак әһәмияткә ия була бара. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү мөһим әһәмияткә ия.

Кече һәм урта эшмәкәрлеккә карата җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең төп юнәлеше - алар өчен уңайлы үсеш шартлары тудыру, эшмәкәрлек потенциалын тулырак ачу һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының көндәшлеккә сәләтен күтәрү өчен шартлар тудыру.

Кече эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыру максатыннан, дәүләт хакимияте органнары һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары, кече эшкуарлыкка ярдәм итү

оешмалары, иҗтимагый берләшмәләр һәм эшкуарларның коммерциячел булмаган оешмалары, кече эшмәкәрлек субъектлары арасында көчләрне һәм килештерелгән гамәлләрне берләштерү зарур. Кече эшкуарлыкка ярдәм итүнең норматив - хокукый базасын, кече эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм күрсәтү механизмнарын һәм финанс механизмнарын үстерү хезмәттәшлек нәтиҗәсе булырга тиеш. Тәҗрибә күрсәткәнчә, икътисадта булган проблемалар, шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлектә, программа методлары белән аеруча нәтиҗәле хәл ителә, чөнки комплекслы якын килү финанс, матди, хезмәт һәм башка ресурсларның өстенлекле юнәлешләрдә рациональ туплануын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Җирлек территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү чараларын гамәлгә ашыру, аның үсешенең төп бурычы - җирлекнең Татарстан Республикасында гамәлдә булган дәүләт һәм республика программалары буенча кече һәм урта эшмәкәрләренә дәүләт ярдәме алу өчен методик һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтү.

Программалы-максатчан алым кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүнең төп проблемаларын түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру юлы белән хәл итүгә юнәлтелгән:
- дәүләт ярдәме чараларын алу өчен документлар әзерләүдә методик ярдәм күрсәтү;
- төп проблемалар һәм проблемаларны хәл итү механизмнары буенча семинарлар һәм «түгәрәк өстәлләр» оештыру һәм уздыру;
- муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) белән тәэмин итүгә субъектларны максималь җәлеп итү эшләрен оештыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлекнең уңай имиджын булдыру һ.б.

Әлеге чараларны гамәлгә ашыру кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү дәрәҗәсен арттырырга мөмкинлек бирәчәк, ул Татарстан Республикасында эшмәкәрлекне заманча үстерүгә кучү таләпләренә туры киләчәк.

Стратегик юнәлешләрне нәтиҗәле гамәлгә ашыруны тәэмин итү кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү нәтиҗәсен билгели, җирлекнең җирле үзидарә органнарына үз тырышлыкларын түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерергә кирәк:

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына гына түгел, барлык кызыксынган якларга перспектив планнар һәм программалар, әлеге өлкәдә Татарстан Республикасы тарафыннан күрелә торган гамәли чаралар һәм адымнар турында тулы һәм оператив мәгълүмат бирү;

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеген җайга сала торган әзерләнә торган норматив хокукый актлар проектлары турында актив фикер алышу өчен җирлек җирле үзидарә органнарының ачыклыгын тәэмин итү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек, иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән аларны кулланунның мөмкин булган нәтиҗәләре турында сөйләшү һ. б.

Кече эшмәкәрлекне үстерү- ул авыл җирлегенең имин киләчәгенә зур өлеш кертү. Нәкъ менә кече бизнес, салым керемнәрен тәэмин итеп, җирлекнең стратегик тотрыклылыгын тәэмин итәргә тиеш.

Программаны кабул итү җирлек территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү өлкәсендәге мәсьәләләрне тагын да сыйфатлырак хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк

## 4. Төп максатлар һәм бурычлар

Программаның төп максатлары:

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү;
- кече һәм урта бизнесны үстерү өчен уңайлы мохит тудыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлекнең гамәлдәге субъектларын саклап калу һәм яңаларын булдыру;
- салым салына торган базаны киңәйтү һәм салымнар һәм җыемнарны җыюны арттыру исәбенә бюджет формалаштыруда кече һәм урта эшмәкәрлекнең кертемен арттыру;
- базарның җирле житештерүчеләр товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре белән туенуы;
- авыл җирлеге халкының мәшгульлеген тәэмин итү.

Куйган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителергә тиеш:

-кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын мәгълүмати яктан һәм консультация белән тәэмин итү;

-кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын методик яктан тәэмин итү;

-кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары предприятиеләренә һәм оешмаларына җирлектәге эшсез халыкны эшкә урнаштыру;

-кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары бизнесында позицияләрне ныгыту;

-кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын булдыру.

-кече һәм урта эшмәкәрлек турында җәмәгатьчелекнең уңай фикерен формалаштыру;

-кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына алар җитештерә торган товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сату, алга җибәрүдә ярдәм күрсәтү;

-бизнес алып бару, кадрларны һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының белем дәрәҗәсен күтәрү өчен шартлар тудыру.

## 5. Программаны гамәлгә ашыру срогы

Программаны гамәлгә ашыру 2024-2026 елларга исәпләнгән.

## 6. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программада каралган чаралар исемлегенә җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

| **Елларга бүленгән программаның финанслау күләме һәм чыганаклары** | Финанслау чыганагы | ел | | | Гамәлгә ашыру чорында барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2024 | 2025 | 2026 | |
| | Җирле бюджет | 1000,00 сум | 1000,00 сум | 1000,00 сум | 3000,00 сум |

## 7. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Әлеге программада билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыру авыл җирлеге башкарма комитеты - программаны эшләүче тарафыннан гамәлгә ашырыла. Программаны гамәлгә ашыру барышында төп әзерләүче аерым башкаручыларның оператив хезмәттәшлеген оештыра. Программаның заказчысы чараларны ачыклый һәм программага үзгәрешләр кертү кирәк булганда, эшне билгеләнгән тәртиптә оештыра.

## 8. Программаны гамәлгә ашыруда контроль

Программаның заказчысы программа чараларының үтәлешен контрольдә тота. Программаны башкаручылар программаны тормышка ашыруның барышы турында авыл җирлеге башкарма комитетына мәгълүмат бирәләр.

## 9. Программаны үтәүдән көтелә торган нәтиҗәләре

Мәгълүмат, консультация, методик тәэмин итү рәвешендә кече эшкуарлык субъектларына муниципаль ярдәм күрсәтүгә бәйле программа чараларын гамәлгә ашыру хуҗалык субъектлары санын арттырырга мөмкинлек бирәчәк, эшсезлек дәрәҗәсенең кимүенә китерәчәк, җирлек бюджетына салым кертемнәрен арттырырга, җирлек халкының мәшгульлеген, үз-үзен эш белән тәэмин ителешен, керемен һәм тормыш дәрәҗәсен арттырырга, җитештерү күләмнәрен арттырырга, продукция сату базарын киңәйтергә, гаилә терлекчелек фермалары санын, авыл хуҗалыгы терлекләренең баш санын арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Шулай ук җирлекнең кече һәм урта эшэшмәкәрлегенең уңай имиджын формалаштырырга, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм җирле үзидарә органнары арасында эшлекле мөнәсәбәтләрне үстерергә ярдәм итәчәк.

## 10. Программа чаралары исемлеге

Югарыда куелган бурычларны әлеге программаны гамәлгә ашыру механизмнары аша хәл итүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән программа чаралары исемлеге әлеге программага кушымтада күрсәтелгән.

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Яңа Спас авыл җирлеге
башкарма комитетының
2024 елның 01 февралендәге
3 номерлы карарына
2 кушымта

**"2024-2026 елларда Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү" муниципаль программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар**

| № п/п | Чаралар исемлеге | Башкаручы | Финанслау чыганагы | Үтәү ср |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүне норматив хокукый һәм оештыру ягыннан тәэмин | | | | |
| 1.1. | 2024-2026 елларга кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән норматив хокукый базаны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү | Җирлек башкарма комитеты | Финансла мыйча | 2024-202 еллар |
| 1.2. | Товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сату базарын киңәйтү, инвестицияләр җәлеп итү максатларында күргәзмәләрдә һәм ярминкәләрдә катнашуга җирлекнең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын җәлеп итүгә ярдәм | Җирлек башкарма комитеты | Финансла мыйча | 2024-202 еллар |
| 1.3. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеген тоташ статистик тикшерүне уздыруга ярдәм итү | Җирлек башкарма комитеты | Финансла мыйча | 2024-202 еллар |
| 1.4. | Авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына эшче белгечлекләре кадрларын әзерләүдә, яңадан әзерләүдә һәм аларның квалификациясен күтәрүдә ярдәм итү | Җирлек башкарма комитеты, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - район Башкарма комитеты) (килешү буенча), "Зәй районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге"(килешү буенча) | ТР бюджеты | 2024-202 еллар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **2. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына консультация, методик һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтү** | | | | |
| 2.1. | Дәүләт ярдәмен алу мәсьәләләре буенча җирлекнен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен консультацияләр оештыру | Җирлек башкарма комитеты | Финансла мыйча | 2024-2026 еллар |
| 2.2. | Эшмәкәрлекне үстерү һәм яклау, эшчәнлекне оештыру һәм алып бару, гамәлдәге законнардагы үзгәрешләр буенча җирлекнең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен семинарлар оештыру | Җирлек башкарма комитеты | Финансла мыйча | 2024-2026 еллар |
| 2.3. | Җирлекнең кече һәмуртаэшкуарлыксубъектлары өчен эшләнгән методик кулланмалар,мәгълүматибуклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләрэшләү юлы беләнкечеһәмуртаэшкуарлыксубъектларынмәгълүматитәэминитүһәмҗирлекнең рәсмисайтындакечеһәмуртаэшкуарлыкныүстерүгәдәүләтярдәме күрсәтүтурындамәгълүматурнаштыру | Җирлек башкарма комитеты | Җирле бюджет | 2024-2026 еллар |
| 2.4. | Авыл җирлегенең рәсми сайтында җирлекнең кече һәм урта бизнес эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру | Җирлек башкарма комитеты | Финансла мыйча | 2024-2026 еллар |
| 2.5. | Җирлекнең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары казанышларын пропагандалау мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек | Җирлек башкарма комитеты | | 2024-2026 еллар |
| 2.6. | Шәхси эшмәкәрләр өчен еллык салым декларациясен төзегәндә юридик һәм практик ярдәм | Җирлек башкарма комитеты | Финансла мыйча | 2024-202 еллар |
| **3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү** | | | | |
| 3.1. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын торак булмаган буш урыннар белән тәэмин итүдә, шулай ук заманча функциональ, технологик, санитар-эпидемиологик, экологик таләпләргә җавап бирә торган җир кишәрлекләре бүлеп бирүдә ярдәм итү | Җирлек башкарма комитеты | Финансла мыйча | 2024-202 еллар |
| **4. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшмә органнары эшчәнлегенә ярдәм итү** | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4.1. | Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшмә органнарына аларның эшчәнлеген гамәлгә ашыруда ярдәм итү | Җирлек башкарма комитеты | Финансламыйча | 2024-2026 еллар |
| 4.2. | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемалары буенча эшлекле очрашулар, «түгәрәк өстәлләр» һәм семинарлар оештыру һәм үткәрүдә катнашу | Җирлек башкарма комитеты, район Башкарма комитеты (килешү буенча) | Финансламыйча | 2024-2026 еллар |
| **5. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен уңай иҗтимагый климат тудыру** | | | | |
| 5.1. | Авыл жирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына инвестиция проектларын формалаштыру һәм тормышка ашыруда ярдәм итү | Җирлек башкарма комитеты | Финансламыйча | 2024-2026 еллар |
| 5.2. | Кече эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегенә мониторинг үткәрү | Җирлек башкарма комитеты | Финансламыйча | 2024-2026 еллар |
| 5.3. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арасында ел саен уздырыла торган конкурсларны үткәрү һәм уңайлы иҗтимагый климат булдыру максатыннан үткәрелә торган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту | Җирлек башкарма комитеты | Район бюджеты | 2024-2026 еллар |